КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 май г.Казань № 423

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2015 ел, 6 май, 328 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2015 ел, 6 май, 328 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел 9 март, 133 нче; 2018 ел, 17 июль, 572 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

1.1 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грантлар Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына грантлар бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан бирелә.»;

III бүлектә:

3.4 нче пунктның беренче абзацында «бер көн эчендә» сүзләрен «эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә» сүзләренә алыштырырга;

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «IV. Грантлар бирү өчен заявкаларны сайлап алуны үткәрү тәртибе

4.1. Конкурста катнашуга законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген конкурс игълан итү көненә кимендә бер ел гамәлгә ашырган, аларның уставлары нигезендә эшчәнлегенең төп максаты татар халкының мәдәни мирасын, телен, тарихын пропагандалау һәм киләчәк буыннарда татар мәдәниятенең этник тиңдәшлеген формалаштыру буенча социаль, мәгълүмати, мәдәни, мәгариф, фәнни функцияләрне гамәлгә ашыру булган, заявка бирү көненә түбәндәге таләпләргә туры килгән иҗтимагый оешмаларга рөхсәт ителә:

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмаган дәүләт һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт (территория) торган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50 процenttан артып киткән Россия юридик затлары булмау;

бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән Татарстан Республикасының башка хокукый актлары нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында башка үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмау;

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

бетерү, үзгәртеп оештыру процессында булмау, аларга карата банкротлык процедурасы башланмаган булу, аларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булу.

4.2. Конкурс үткәрү турындагы белдерү вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарыла һәм анда конкурсны үткәрү вакыты, урыны һәм тәртибе, заявкаларны кабул итү башлану һәм тәмамлану вакыты турында мәгълүматлар бирелә.

Заявкаларны кабул итү конкурс үткәрү турында белдерү басылып чыккан көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

4.3. Конкурста катнашу өчен вәкаләтле органга түбәндәге документлар тапшырыла:

бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтадагы форма буенча язылган, шул исәптән заявка бирү көненә карата түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган заявка:

иҗтимагый оешманың бетерү, үзгәртеп оештыру процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы башланмавы, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы турында;

иҗтимагый оешманың бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы булмавы турында;

иҗтимагый оешманың субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән Татарстан Республикасының башка хокукый актлары нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында башка үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмавы турында;

иҗтимагый оешманың салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавы турында;

иҗтимагый оешманың чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмаган дәүләт һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт (территория) торган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50 процентган артып киткән Россия юридик заты булмавы турындагы;

бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча проект тасвирламасы;

иҗтимагый оешма уставының иҗтимагый оешма мөһере (булганда) һәм аның җитәкчесе имзасы белән расланган күчермәсе;

проектны тормышка ашыру чыгымнарының гомуми суммасыннан кимендә 20 процент күләмендә бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән проектны финанслашу турында ирекле формадагы гарантия хаты;

тапшырыла торган документлар исемлеге.

Министрлык дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә түбәндәге документларны соратып ала:

юридик затны салым органында исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен;

салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазен.

4.4. Грантлар бирү шартлары түбәндәгеләр була:

иҗтимагый оешманы конкурста җиңүче дип тану;

иҗтимагый оешманың проектны тормышка ашыру чыгымнарының гомуми суммасыннан кимендә 20 процент күләмендә бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән проектны финанслашу буенча йөкләмәсе булуы;

иҗтимагый оешмага карата вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грантлар бирү максатларының, шартларының, тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалык булу.

4.5. Бирелә торган грант хисабыннан иҗтимагый оешма проект бюджетында түбәндәгеләрне күздә тотарга хокуклы:

проектны тормышка ашыру өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне;

проектны тормышка ашыруга бәйле командировка чыгымнарын;

проектны тормышка ашыруның календарь планында каралган чараларны гамәлгә ашыруга турыдан-туры бәйле булган башка чыгымнарны.

4.6. Проект бюджетында грант акчасы хисабыннан түбәндәгеләргә бәйле чыгымнарны финанслау каралмаска тиеш:

эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм коммерция оешмаларына ярдәм күрсәтүгә;

проект белән турыдан-туры бәйле булмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга;

сәяси партияләргә һәм сайлау кампанияләренә ярдәм күрсәтүгә;

митинглар, демонстрацияләр, пикетлар үткәрүгә;

алкогольле эчемлекләр һәм тәмәке продукциясе сатып алуга;

штрафлар түләүгә;

иҗтимагый оешманың агымдагы чыгымнарына (иҗтимагый оешма хезмәткәрләренең эш хакы, урын арендасы, шулай ук заявка бирү вакытына тормышка ашырылган булган яки агымдагы чаралар чыгымнары);

коммерцияле проектларга;

артистлар эшенә түләүгә;

проектны тормышка ашыру өчен таләп ителми торган җиһаз һәм оештыру техникасы сатып алуга;

офис җиһазы сатып алуга;

җәмәгать оешмалары урыннарында, биналарында ремонт эшләре үткәрүгә;

проектны тормышка ашыру планында каралмаган чараларны үткәрүгә;

ягулык-майлау материаллары чыгымнарына.

Китаплар, уку ярдәмлекләре, методик материаллар, альбомнар бастырып чыгару, фильмнар, телевизион һәм радиопрограммалар булдыру аларның максаты булган проектлар бюджетларында грант акчасы исәбеннән авторлык бүләкләүләре һәм гонорарлар өчен түләү, әлеге материалларны тарату яки күрсәтү (демонстрацияләү) чыгымнарын финанслау каралмаска тиеш.

4.7. Бер иҗтимагый оешма бары бер заявка гына бирергә, аның составында конкурста катнашу өчен бер проект кына тәкъдим ителергә мөмкин.

4.8. Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар вәкаләтле органга конкурс үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән адрес буенча һәм кабул итү сәгатьләрендә йә почта аша кәгазьдә яки, иҗтимагый оешма Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында теркәлгән очракта, Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы ярдәмендә иҗтимагый оешманың вәкаләтле затының электрон имзасы белән электрон рәвештә бирелә.

Кәгазьдә бирелә торган заявка һәм аңа теркәлә торган документлар тегелгән, номерланган һәм иҗтимагый оешманың вәкаләтле заты имзасы һәм мөһере (булганда) белән таныкланган булырга тиеш. Барлык документлар төгәл басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр ясау рөхсәт ителми (иҗтимагый

оешманың вәкаләтле заты имзасы белән расланган һәм мөһере (булганда) белән беркетелгән төзәтмәләрдән тыш).

4.9. Заявканы кәгазьдә кабул иткәндә вәкаләтле орган аны кергән көнне заявкаларны исәпкә алу журналында терки һәм иҗтимагый оешмага, заявканы алу көнен һәм бирелгән теркәү номерын күрсәтеп, аны алу турында расписка бирә.

Заявка Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы аша кергән очракта, вәкаләтле орган аны кергән көнне заявкаларны исәпкә алу журналында терки һәм киләсе эш көнендә иҗтимагый оешмага, заявканы алу көнен һәм бирелгән теркәү номерын күрсәтеп, аны алу турында расписка җибәрә.

Заявка вәкаләтле органга почта аша кергәндә ул бер эш көне эчендә заявкаларны исәпкә алу журналында теркәлә. Бу очракта заявка алу турында расписка язылмый, заявкаларны исәпкә алу журналында теркәлү көне итеп почта аша алу көне күрсәтелә.

4.10. Вәкаләтле орган заявкаларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә барлык кергән заявкаларны Советка тапшыра.

4.11. Тапшырылган заявкалар Совет тарафыннан вәкаләтле орган заявкаларны тапшырган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә бу Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвенә карап тикшерелә.

4.12. Совет түбәндәге нигезләрдә конкурста катнашудан баш тарту турында карар кабул итә:

иҗтимагый оешмаларның бу Тәртипнең 4.1 нче пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

заявканы һәм документларны заявкаларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән соң бирү.

Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән иҗтимагый оешмалар исемлеге һәм конкурста катнашудан баш тартылган иҗтимагый оешмалар исемлеге Совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.13. Совет утырышы беркетмәсен раслаганнан соң, конкурста катнашырга рөхсәт ителгән иҗтимагый оешмалар исемлеге һәм конкурста катнашудан баш тартылган иҗтимагый оешмалар исемлеге эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

4.14. Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән иҗтимагый оешмалар исемлеген раслаганнан соң, Совет заявкаларны һәм аларга теркәлгән документларны эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Совет тарафыннан расланган экспертлар исемлегенә кертелгән экспертларга карап тикшерүгә тапшыра.»;

V бүлектә:

5.8 һәм 5.9 нчы пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Совет эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә конкурста җиңүчеләр исемлеген һәм бу Тәртипнең 6.1 нче пункты нигезендә аларга бирелә торган грантлар күләмен билгели һәм грант бирү йә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Грант бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

иҗтимагый оешма тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 4.3, 4.7, 4.8 нче пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

иҗтимагый оешма тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

иҗтимагый оешмага карата вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грантлар бирү максатлары, шартлары, тәртибе үтәлүен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалык булмау.

Совет карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

5.9. Конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары (конкурста катнашучылар турында мәгълүмат, рейтинг, бирелә торган грантлар күләмен күрсәтеп расланган конкурста җиңүчеләр исемлеге) аларны раслаган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

VI бүлектә:

6.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Сорала торган грант күләме бу пунктта күрсәтелгән формула буенча исәпләп чыгарылган суммадан артып киткән очракта, бирелә торган грант күләме бу пунктта күрсәтелгән формула буенча исәпләп чыгарылган суммага туры килә.

Сорала торган грант күләме бу пунктта күрсәтелгән формула буенча исәпләп чыгарылган суммадан кимрәк булган очракта, бирелә торган грант күләме сорала торган суммага туры килә.»;

6.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Грант бирү турында карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә вәкаләтле орган конкурста җиңүчеләр белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган бертип форма буенча грантлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант күләме;

грантның максатчан билгеләнеше;

бу Тәртипнең 6.3 нче пунктында билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре;

грант күчерү тәртибе һәм вакытлары;

вәкаләтле органның өстәмә хисаплылык вакытларын һәм формаларын билгеләү хокукы;

бу Тәртиптә күрсәтелгән очракларда, грантны кире кайтару тәртибе;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрү вакытлары;

грант алучының вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грант бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

килешү шартларын бозган өчен җаваплылык.

Вәкаләтле орган тарафыннан грантны күчерү яклар тарафыннан килешүгә имза куелган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Россия кредит оешмаларындагы исәп-хисап счетына килешү нигезендә башкарыла.

Җиңүче тарафыннан грант бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлмәгән очракта, вәкаләтле орган конкурста җиңүчеләр белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган бертип форма буенча килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Иҗтимагый оешма грант акчасы керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.3 нче пункт өстәргә:

«6.3. Грант бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр була:

проектны үтәү күләме (процентта);

проектны тормышка ашыру вакытларын үтәү (процентта);

проектны тормышка ашыру кысаларында үткәрелгән чараларда (алга таба – чаралар) катнашучылар саны (берәмлектә);

массакүләм мәгълүмат чараларында чаралар турында уңай басмалар саны (берәмлектә).»;

VIII бүлектә:

8.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Грантлар алучылар вәкаләтле органга агымдагы елның 1 декабренә кадәр, фото- һәм видеоматериалларны теркәп, бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада бирелгән форма бенча грант бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап кертә.»;

8.2 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган грантлар бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«грант бирү нәтиҗәләренә ирешү.»;

8.6 нчы пунктта «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» сүзләрен «вәкаләтле орган» сүзләренә алыштырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада:

«гариза бирүче оешма» һәм «оешма» сүзләрен тиешле килешләрдәге «иҗтимагый оешма» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 9 нчы пункт өстәргә:

«9. Гариза бирү көненә карата түбәндәгеләрне раслыйм:

иҗтимагый оешманың бетерү, үзгәртеп оештыру процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы башланмавын, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын;

иҗтимагый оешманың Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2015 ел, 6 май, 328 нче карары белән расланган Россия Федерациясе төбәкләрендә этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү тәртибенең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы булмавын;

иҗтимагый оешманың субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән Татарстан Республикасының башка хокукый актлары нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында башка үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмавын;

иҗтимагый оешманың салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын;

иҗтимагый оешманың чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмаган дәүләт һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт (территория) торган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмавын.

Иҗтимагый оешмага карата Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грантлар бирү максатларының, шартларының, тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризамын.»;

«Ф.Ис.Ат.ис.» сүзләреннән соң «(соңгысы булганда)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада «Ф.Ис.Ат.ис.» сүзләреннән соң «(соңгысы булганда)» сүзләрен өстәргә;

3 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә;

әлеге карар белән расланган Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш) этномәдәни проектларны тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү советы составын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 25 май, 423 нчы
карарына 3 нче кушымта

Форма

Грант бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап

______________________________________________________________________
(проектның исеме)

| Грант бирү нәтиҗәсенең исеме | Грант бирү нәтиҗәсенең планлаштырыла торган мәгънәсе | Грант бирү нәтиҗәсенең фактагы мәгънәсе |
|---|---|---|
| Проектны үтәү күләме, процент | | |
| Проектны тормышка ашыру вакытларын үтәү, процент | | |
| Проектны тормышка ашыру кысаларында үткәрелгән чараларда катнашучылар саны, кеше | | |
| Массакүләм мәгълүмат чараларында проектны тормышка ашыру кысаларында үткәрелгән чаралар турында уңай басмалар саны, берәмлек | | |

Проектның куелган максатларына, бурычларына ирешү: ________________________
Проектны алга таба тормышка ашыру һәм аны тиражлау мөмкинлеге:
___________________________________________________________________________
Проектны тормышка ашыру кысаларында үткәрелгән чараларның социаль әһәмияте:
___________________________________________________________________________

Грант бирү нәтиҗәләренең фактагы мәгънәләрен раслый торган бухгалтерлык һәм башка документларның күчермәләре, теркәләләр.

Иҗтимагый оешма җитәкчесенең
Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы булганда)

_____________________________________________/______________________/
(имзасы)

М.У.

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 6 май, 328 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 25 май, 423 нче
карары редакциясендә)

Россия Федерациясе төбәкләрендә (Татарстан Республикасыннан тыш)
этномәдәни проектларны гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмаларга
ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте
грантларын конкурс нигезендә бирү советы
составы

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, Совет рәисе |
| Гыйльметдинов Илдар Ирек улы | «Федераль татар милли-мәдәни автономиясе» иҗтимагый оешмасы советы рәисе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Закиров Ринат Зиннур улы | Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисенең беренче урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Совет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әдһәмова Юлия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Вәлиев Рафаэль Миргасыйм улы | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты директорының фәнни эшчәнлек буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Габдрахманова Гөлнара Фаат кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең этносоциологик тикшеренү-ләр бүлеге мөдире |
| Заһидуллина Дания Фатыйх кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президенты |

| | |
|---|---|
| Миңнуллин Ким Мөгаллим улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры |
| Миргалимов Илдар Флүс улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары |
| Мифтахова Алсу Равил кызы | «Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |
| Мостафин Данил Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментына караган Милли сәясәтне тормышка ашыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Низамова Ләйсән Гәптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Салихов Данил Хәбибрахман улы | «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Сафиуллина Рәисә Гариф кызы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча). |